**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

17.03.2020 ел №163

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 мартындагы 87 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законнары, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 мартындагы 87 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән (2018 елның 23 апрелендәге 95 номерлы, 2019 елның 24 августындагы 104 номерлы, 2019 елның 5 февралендәге 127 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 138 номерлы, 2019 елның 20 сентябрендәге 143 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Шешминка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.6.1. бүлекнең 2 пунктчасын бәян итәргә: «3) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел

профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашудан тыш) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы вәкиленең рөхсәте белән;

в) «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар».

1.2. 7.2.3 пунктчаны бәян итәргә: «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Шешминка авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе: М.Д.Шәйхетдинов